| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ КУКМОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОН СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 24 июле Кукмара ш. № 302

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советының 2018 елның 16 ноябрендәге 187 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе турындагы Положениене яңа редакциядә раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 41 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә мәгариф системасында психологик-педагогик хезмәтләрне үстерү һәм сәләтле балаларны ачыклау һәм аларга ярдәм итү өчен шартлар тудыру, олимпиада һәм конкурс хәрәкәтенә җәлеп ителгән муниципаль белем бирү учреждениеләрендә укучыларның өлешен арттыру, аларны предмет олимпиадаларына әзерләү максатыннан Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советының 2018 елның 16 ноябрендәге 187 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе турындагы Положениене кушымта итеп бирелә торган редакциядә расларга.

2. Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – Мәгариф идарәсе башлыгы Мансуров Роберт Мияссәр улына, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән нигезләмәне раслауга бәйле рәвештә юридик затларның Бердәм дәүләт реестрына кертелергә тиешле үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алганда гариза бирүче буларак чыгыш ясарга йөкләргә. Бу максатларда әлеге пунктта күрсәтелгән затка гаризаларга һәм башка документларга имза салырга һәм башка кирәкле гамәлләр һәм формальностьларны үтәргә вәкаләт бирергә.

**Район Башлыгы** **С. Д. Димитриев**

Кукмара муниципаль районы Советының 2020 елның 24 июлендәге 302 номерлы карарына кушымта

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесе турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесе (алга таба − мәгариф идарәсе) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Уставы, Кукмара районы Советының 2010 елның 20 декабрендәге 30 номерлы «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф бүлеге исемен үзгәртү турында» карары нигезендә идарә функцияләрен гамәлгә ашыру максатларында төзелде.

1.2. Мәгариф идарәсе Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба − Башкарма комитет) органы булып тора, юридик затларны теркәү турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә аны дәүләт теркәвенә алганнан бирле юридик зат статусына ия.

Мәгариф идарәсе Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнарының законнар һәм муниципаль хокукый актлары (алга таба – муниципаль хокукый актлар) нигезендә идарә итүне гамәлгә ашыра.

Мәгариф идарәсе Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының җирле үзидарә органы булып тора.

1.3. Мәгариф идарәсен гамәлгә куючы – Татарстан Республикасының «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге.

Татарстан Республикасының «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Мәгариф идарәсе милке хуҗасы булып тора. Милекче вәкаләтләрен законнар һәм муниципаль хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы гамәлгә ашыра.

1.4. Мәгариф идарәсе юридик зат булып тора, мөстәкыйль балансканың, бюджет сметасына, мөһер, үз исеме язылган штамплар һәм бланкларга, оператив Идарәдә аерымланган мөлкәткә, Россия Федерациясе Бюджет Кодексы нигезендә ачыла торган шәхси счетка ия.

Мәгариф идарәсе, законнар һәм муниципаль хокукый актлар таләпләрен үтәп, банкларда һәм башка кредит оешмаларында исәп-хисап һәм башка счетлар ачарга хокуклы.

1.5. Мәгариф идарәсе гражданлык әйләнешендә үз исеменнән катнашырга, милек һәм башка хокукларны сатып алырга һәм гамәлгә ашырырга, законнарда, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Уставында, әлеге Нигезләмәдә һәм гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнгән чикләрдә вазыйфа башкарырга хокуклы.

Мәгариф идарәсе судта, арбитраж һәм третей судларында гариза бирүче һәм җавап бирүче булырга мөмкин.

1.6. Мәгариф идарәсенең исеме:

1.6.1. рус телендә:

- тулы исеме: «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесе;

- кыскартылган исеме: «Кукмара муниципаль районы Мәгариф идарәсе» МУ.

1.6.2. татар телендә: «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесе.

1.7. Мәгариф идарәсенең урнашкан урыны: 422110, Татарстан Республикасы, Кукмара шәһәре, Эшчеләр тыкрыгы, 7 нче йорт.

Мәгариф идарәсенең юридик адресы: 422110, Татарстан Республикасы, Кукмара шәһәре, Эшчеләр тыкрыгы, 7 нче йорт.

1.8. Мәгариф идарәсе мөлкәте аңа милекче тарафыннан оператив идарә итү хокукында беркетелә. Җир кишәрлекләре Мәгариф идарәсенә җир законнары нигезендә бирелә.

1.9. Мәгариф идарәсе аларга оператив идарә хокукында беркетелгән мөлкәт белән, акча средстволары белән идарә итүне, алардан файдалануны һәм алар белән эш итүне законнарда каралган тәртиптә һәм чикләрдә башкара.

1.10. Мәгариф идарәсенең мөлкәте һәм акчалары аның балансында чагыла һәм гамәлдәге законнар нигезендә кулланыла.

1.11. Милекче үзе тарафыннан Мәгариф идарәсенә беркетелгән яисә әлеге мөлкәтне сатып алуга милекче тарафыннан бүлеп бирелгән акчалар хисабына Мәгариф идарәсе тарафыннан сатып алынган артык, файдаланылмый яки билгеләнеше буенча файдаланылмый торган мөлкәтне тартып алырга хокуклы. Мәгариф идарәсеннән тартып алынган мөлкәт белән милекче үз теләге буенча эш итәргә хокуклы.

1.12. Мәгариф идарәсенең структурасы һәм штат расписаниесе расланган структура, хезмәткәрләрнең билгеләнгән чик саны һәм хезмәткә түләү фонды нигезендә Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан раслана.

Мәгариф идарәсе составында түбәндәгеләр үз эшчәнлеген башкара:

- Мәгариф идарәсенең методик кабинеты (алга таба – методик кабинет);

- Мәгариф идарәсе каршындагы психологик-педагогик хезмәт (алга таба– психологик-педагогик хезмәт);

- Мәгариф идарәсе каршындагы олимпиада үзәге (алга таба – олимпиада үзәге).

1.13. Мәгариф идарәсе эшчәнлеген финанс ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына һәм бюджет сметасы нигезендә башкарыла.

1.14. Мәгариф идарәсенә казна учреждениесенә карата билгеләнгән законнар таләпләре тарала.

1.15. Мәгариф идарәсе тибын бетерү, үзгәртеп кору һәм үзгәртү законнарда каралган тәртиптә һәм формаларда гамәлгә ашырыла. Шул ук вакытта тиешле карар Кукмара муниципаль районы Советы (алга таба – район Советы) тарафыннан кабул ителә.

1.16 Әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү район Советы карары белән башкарыла.

## II. Мәгариф идарәсе эшчәнлегенең предметы, максатлары һәм бурычлары

2.1. Мәгариф идарәсе эшчәнлегенең предметы һәм максаты – үз компетенциясе кысаларында һәм Мәгариф идарәсенә бу максатларга бүлеп бирелгән матди ресурслар һәм финанс чаралары кысаларында мәгариф өлкәсендә муниципаль районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча идарә функцияләрен үтәү, ә атап әйткәндә:

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру (федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү вәкаләтләреннән тыш);

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Мәгариф идарәсенә караган муниципаль белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыру (финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган өстәмә белем бирүдән тыш);

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Мәгариф идарәсенә караган муниципаль белем бирү оешмаларында балаларны карап тору һәм карау, балаларны тоту өчен шартлар тудыру, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә үз вәкаләтләре чикләрендә балаларның каникул вакытында ялын оештыруны тәэмин итү чараларын, шул исәптән аларның тормыш һәм сәламәтлеге куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру;

- белем бирү өлкәсендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы законнары һәм Уставы нигезендә билгеләнгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

Мәгариф идарәсе балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау эшчәнлегендә законнар һәм муниципаль хокукый актлар нигезендә катнаша.

2.2. Мәгариф Идарәсенең төп бурычлары:

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә белем бирү өлкәсендә гражданнарның (физик затларның) конституцион гарантияләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү;

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә белем бирүне камилләштерүне тәэмин итү;

- үз компетенциясе кысаларында балаларның ял һәм сәламәтләндерү хокукларын тәэмин итү;

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә эшчәнлекләре балаларны ял иттерүгә һәм сәламәтләндерүгә юнәлдерелгән учреждениеләрне саклау һәм үстерү;

- үз компетенциясе кысаларында балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген, сукбайлыгын, хокук бозуларын һәм җәмгыятькә каршы гамәлләрен кисәтүне, моңа этәрә торган сәбәпләрне һәм шартларны ачыклау һәм бетерүне тәэмин итү; үз компетенциясе кысаларында балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү; социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнарны социаль-педагогик тернәкләндерү; үз компетенциясе чикләрендә балигъ булмаганнарны җинаять кылуга һәм җәмгыятькә каршы гамәлләр кылуга җәлеп итү очракларын ачыклау һәм туктату.

2.3. Методик кабинетның эшчәнлеге предметы һәм максаты булып Татарстан Республикасы законы белән атарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының җирле үзидарә органнарына тапшырылган мәгариф эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү тора.

2.4. Методик кабинетның бурычлары:

- мәгарифне үстерү буенча федераль һәм региональ программаларны тормышка ашыруны тәэмин итү;

- педагогик хезмәткәрләрнең белем бирү ихтыяҗларын канәгатьләндерү;

– Кукмара муниципаль районы белем бирү оешмаларына (алга таба – муниципаль белем бирү учреждениеләре) белем бирүне үстерү программаларын гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтү һәм әлеге оешмаларның эшчәнлеген методик яктан тәэмин итү;

- яңа белем бирү технологияләрен, белем бирү ресурсларын эшләүне, апробацияләүне һәм гамәлгә кертүне тәэмин итү;

- алдынгы педагогик тәҗрибәне өйрәнү, гомумиләштерү һәм аны муниципаль белем бирү учреждениеләрендә тарату;

- педагогик тәҗрибә һәм аның белән эшләү турында мәгълүматлар банкын булдыру;

- Кукмара муниципаль районы территориясендә мәгариф системасы турында мәгълүматны гомумиләштерү һәм әлеге мәгълүматны тарату.

2.5. Әлеге нигезләмәнең 2.4 пунктында күрсәтелгән бурычларга ирешү өчен методик кабинет законнарда билгеләнгән тәртиптә түбәндәге эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыра:

2.5.1. диагностик-прогностика эшчәнлеге:

- муниципаль белем бирү учреждениеләре педагогик хезмәткәрләренең белем бирү системасы турында мәгълүмат белән бәйле сорауларын һәм ихтыяҗларын өйрәнү;

- педагогик осталыкны диагностикалау;

- социологик тикшеренүләрне оештыру, координацияләү һәм үткәрү; муниципаль белем бирү учреждениеләренең социаль-психологик хезмәтен контрольдә тоту;

- белем бирү системасы мониторингын тормышка ашыруда Мәгариф идарәсе белгечләренә ярдәм күрсәтү;

2.5.2. мәгълүмати-аналитик эшчәнлек:

- белем бирү системасы турында мәгълүматлар банкын булдыру, аны даими тулыландыру;

- муниципаль белем бирү учреждениеләре өчен укыту-методик комплектлар формалаштыру;

- муниципаль белем бирү учреждениеләренә яңа кайткан уку-укыту һәм укыту-методик әдәбият, педагогик фәннең казанышлары, белем бирү оешмаларының алдынгы педагогик тәҗрибәсе турында үз вакытында хәбәр итү;

- уку дисциплиналары буенча күргәзмә әдәбияты фондын, медиатека формалаштыру;

- мәгълүмат-библиография эшчәнлеген алып бару;

2.5.3. мәгълүматлаштыру өлкәсендә эшчәнлек:

- «Татарстан Республикасында Электрон мәгариф» мәгълүмат системасында эшне оештыру;

- белем бирү учреждениеләренә уку процессын мәгълүматлаштыру, мәктәпара компьютер челтәрләрен үстерү мәсьәләләрендә ярдәм күрсәтү;

- муниципаль белем бирү учреждениеләре эшчәнлегендә заманча мәгълүмати-коммуникацион технологияләр куллануны тәэмин итү;

2.5.4. мәгариф эчтәлеген тәэмин итү эшчәнлеге:

- федераль дәүләт белем бирү стандартларын кертү буенча муниципаль белем бирү учреждениеләренең педагогик хезмәткәрләре белән эш;

- муниципаль белем бирү учреждениеләрендә белем һәм укытуның яңа эчтәлеген кертүне дидактик һәм методик тәэмин итү;

- яңа педагогик технологияләрне пропагандалау һәм муниципаль белем бирү учреждениеләренә аларны үзләштерүдә ярдәм күрсәтү;

2.5.5. мәгариф өлкәсендә эксперименталь һәм инновацион эшчәнлек:

- Кукмара муниципаль районы территориясендә һәм муниципаль белем бирү учреждениеләрендә мәгарифне үстерү программаларын эшләүдә катнашу;

- инновацияләрне оештыру һәм экспертиза;

- Кукмара муниципаль районы базасында федераль һәм төбәк дәрәҗәсендәге эксперименталь мәйданчыклар (лабораторияләр, стажер мәйданчыклары, иҗади остаханәләр һәм төркемнәр, укытучыларның фәнни җәмгыятьләре) оештырганда тәҗрибә-эксперименталь эшнең нәтиҗәлелеген оештыру һәм күзәтү;

- эшчәнлек һәм үсеш режимында эшләүче муниципаль белем бирү учреждениеләре белән методик эшне оештыру;

- фәнни-методик эшкә чыгымнар сметасын формалаштыру, муниципаль белем бирү учреждениеләренең педагогик хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү;

2.5.6. квалификация күтәрү өлкәсендә эшчәнлек:

- муниципаль белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренең һәм педагогик хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү;

- Кукмара муниципаль районы өчен кирәк булган белгечлекләр буенча икенче югары белем алып, педагогик хезмәткәрләрне яңадан әзерләүне оештыру;

- башлангыч гомуми, төп гомуми һәм (яки) урта гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген төп максат итеп гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү учреждениеләре гаризалары буенча методик хезмәт күрсәтү;

- мәктәпләрнең педагогик хезмәткәрләргә һәм яшь белгечләргә педагогик ярдәм күрсәтү эше;

- төрле методик юнәлешләр буенча иҗади төркемнәр булдыру һәм үстерү;

- актуаль проблемалар буенча һөнәри консультацияләр күрсәтү;

- район педагогик конференцияләре, педагогик укулар һәм күргәзмәләр, конкурслар әзерләү һәм үткәрү;

2.5.7. аттестация өлкәсендә эшчәнлек:

- муниципаль белем бирү учреждениеләре җитәкчеләрен һәм педагогик хезмәткәрләрен аттестацияләүне оештыру һәм мондый аттестациядә катнашу;

- аттестация өчен документлар эшләү;

- семинарлар, практикумнар, экспертизалар үткәрү;

- муниципаль белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренең һәм педагогик хезмәткәрләренең инновацион һәм тикшеренү эшләрен анализлауда катнашу;

2.5.8. Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – Мәгариф идарәсе башлыгы йөкләмәсе буенча эшчәнлекнең башка төрләре.

2.6. Психологик-педагогик хезмәт эшчәнлегенең предметы һәм максатлары:

- муниципаль белем бирү учреждениеләрендә укучы балаларга, аларның сәләтенә, һәвәслекләренә, кызыксынуларына, сәламәтлекләренә карап, психологик-педагогик ярдәм күрсәтү,

- муниципаль белем бирү учреждениеләрендә укучыларның һәм белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучыларның физик, психик, социаль сәламәтлеген саклау һәм ныгыту өчен шартлар тудыручы бердәм белем бирү мохитен формалаштыру;

- муниципаль белем бирү учреждениеләренең педагогик хезмәткәрләренә, муниципаль белем бирү учреждениеләрендә укучы балигъ булмаган балаларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) укучыларны тәрбияләүдә һәм укытуда ярдәм итү.

2.7. Психологик-педагогик хезмәтнең бурычлары:

- физик һәм психик сәламәтлектә тайпылышларны профилактикалау, шулай ук муниципаль белем бирү учреждениеләрендә укучыларны үстерүдә;

- муниципаль белем бирү учреждениеләре укучыларының сәламәт яшәү рәвешенә мотивациясен формалаштыру;

- муниципаль белем бирү учреждениеләрендә укучы шәхеснең үзбилгеләнешен тәэмин итү, үз-үзен тормышка ашыру өчен шартлар тудыру, муниципаль белем бирү учреждениеләрендә укучыларның һәр яшь этабында шәхси, интеллектуаль үсешенә ярдәм итү;

- муниципаль белем бирү учреждениеләрендә социаль хәлне педагогик һәм психологик анализлау, төп проблемаларны ачыклау һәм аларның килеп чыгу сәбәпләрен, аларны чишү юлларын һәм чараларын билгеләү;

- муниципаль белем бирү учреждениеләренең педагогик коллективларына учреждениедә социаль-психологик климатны гармонияләштерүдә ярдәм итү;

- баланың хокукларын, иреген һәм законлы мәнфәгатьләрен бозган, аның тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудырган очракта, гаилә, муниципаль белем бирү учреждениеләре белән үзара хезмәттәшлек итү;

- муниципаль белем бирү учреждениеләренең педагогик хезмәткәрләре белән берлектә өзлексез белем бирү процессында эзлекле дәвамчанлыкның психологик-педагогик шартларын әзерләүдә һәм булдыруда катнашу;

- муниципаль белем бирү учреждениеләре эшчәнлегенә илебез һәм чит ил педагогикасы, психология, логопедия өлкәсендә ирешелгән казанышларны таратуга һәм гамәлгә кертүгә ярдәм итү;

- яшүсмерләр девиациясен профилактикалау, муниципаль белем бирү учреждениеләре укучыларының социаль дезадаптациясен ачыклау һәм коррекцияләү.

2.8. Әлеге Нигезләмәнең 2.7 пунктында күрсәтелгән бурычларга ирешү өчен, психологик-педагогик хезмәт законнарда билгеләнгән тәртиптә түбәндәге эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыра:

- муниципаль белем бирү оешмаларында балаларның психик, физик үсеше, социаль яшәү шартлары дәрәҗәсен диагностикалау;

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә балалар белән психоррекцион һәм үстерелешле эшчәнлек;

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә психологик-педагогик профилактика эшчәнлеге;

- консультатив эшчәнлек;

- мәгърифәтчелек эшчәнлеге;

- Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – Мәгариф идарәсе башлыгы йөкләмәсе буенча башка төр эшчәнлек алып бару.

2.9. Олимпиада үзәге эшчәнлегенең темасы һәм максаты – Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә балалар һәм яшьләрнең балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен, өстәмә белем бирүне, мәшгульлеген оештыру, оештыру-мәгълүмати һәм фәнни-методик ярдәм күрсәтү буенча чараларын гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру.

2.10. Олимпиада үзәгенең бурычлары:

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә сәләтле затларны ачыклау һәм аларга ярдәм итү;

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә белем бирү, фәнни (фәнни-тикшеренү) эшчәнлегендә, иҗади эшчәнлектә уңышларга ирешкән затларны ачыклау һәм аларга ярдәм итү;

- Олимпиада һәм конкурс хәрәкәтенә җәлеп ителгән муниципаль белем бирү учреждениеләре укучыларын колачлау өлешен арттыру һәм аларны фән олимпиадаларына әзерләүне тормышка ашыру.

2.11. Әлеге Нигезләмәнең 2.10 пунктында күрсәтелгән бурычларга ирешү өчен олимпиада үзәге законнарда билгеләнгән тәртиптә түбәндәге эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыра:

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә үткәрелә торган мәктәп укучылары олимпиадаларын, башка интеллектуаль, иҗади конкурсларны оештыручыларга ярдәм күрсәтү;

- муниципаль белем бирү учреждениеләре укучыларын укучылар олимпиадаларында, башка интеллектуаль, иҗади конкурсларда катнашу максатларында, шул исәптән индивидуаль сәләтләргә мониторинг ясау, төркем һәм индивидуаль консультацияләр бирү, коррекция һәм үстерү эше, тренинглар, семинарлар үткәрү юлы белән педагогик һәм психологик әзерләүне тәэмин итү;

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә иң яхшы сәләтләрен күрсәткән балаларны ачыклау, аларны алга таба үстерү мониторингы мәсьәләләре буенча педагогик хезмәткәрләр катнашында семинарлар, тренинглар, консультацияләр, конференцияләр һәм башка чаралар оештыру һәм үткәрү;

- Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – Мәгариф идарәсе башлыгы йөкләмәсе буенча башка төр эшчәнлек алып бару.

2.12. Мәгариф идарәсе үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте, федераль башкарма хакимият органнары актларына, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Законнары, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Башкарма хакимияте органнары актларына, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Уставына, әлеге Нигезләмәгә һәм башка муниципаль хокукый актларга таяна.

## III. Мәгариф идарәсе вәкаләтләре

3.1. Мәгариф идарәсе, Башкарма комитет органы буларак һәм мәгариф идарәсенә бу максатларга бүлеп бирелгән матди ресурслар һәм финанс чаралары чикләрендә түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

3.1.1. федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү вәкаләтләреннән тыш, муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру (федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү вәкаләтләреннән тыш);

3.1.2. (финанс тәэминаты Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган Балаларга өстәмә белем бирүдән тыш), муниципаль белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыру;

3.1.3. муниципаль белем бирү учреждениеләрендә балаларны карап тору һәм карау, балаларны карап тоту өчен шартлар тудыру;

3.1.4. мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешле балаларны исәпкә алу;

3.1.5. дәрестән тыш һәм каникул вакытында балаларның ялын, сәламәтләндерүне, хезмәт һәм мәшгульлеген оештыруда катнашу; эшчәнлеге балаларны ял иттерүгә һәм сәламәтләндерүгә юнәлтелгән учреждениеләрне саклап калуны һәм үстерүне тәэмин итү;

3.1.6. законнар һәм муниципаль хокукый актлар нигезендә муниципаль белем бирү учреждениеләрен төзү, үзгәртеп кору һәм бетерү, муниципаль белем бирү учреждениеләре уставларын эшләүдә катнашу; Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә муниципаль белем бирү учреждениеләре челтәрен үстерү; законнар һәм муниципаль хокукый актлар нигезендә ведомство карамагындагы ведомство карамагындагы муниципаль бюджет учреждениеләре өчен муниципаль биремнәрне формалаштыру һәм раслау;

3.1.7. законнарда һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән чикләрдә федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә эшләнгән муниципаль белем бирү учреждениеләре эшчәнлеген, күрсәтелә торган белем бирү хезмәтләренең сыйфатын, уку планнарының, үрнәк белем бирү программаларының үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру;

3.1.8. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә белем бирүне үстерүгә ярдәм итү максатларында оешмаларны гамәлгә куюда катнашу;

3.1.9. заказларны урнаштыру һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә муниципаль контрактлар төзү, шулай ук мәгариф идарәсе компетенциясенә кертелгән мәсьәләләрне хәл итү, мәгариф идарәсенең башка функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар китерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә граждан-хокукый шартнамәләр төзү;

3.1.10. мәгариф белән идарә итү өлкәсенә караган мәсьәләләр буенча конференцияләр, киңәшмәләр, очрашулар, семинарлар, күргәзмәләр һәм башка чаралар үткәрү;

3.1.11. халыкны белем бирү хезмәтләре белән тәэмин итүнең район программаларын эшләү, законнар һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә карау һәм раслау өчен программалар проектларын тәкъдим итү;

3.1.12. гражданнарның ана телендә белем алу хокукларын гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;

3.1.13. сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр белән эшләү, аларның белем алу, үсеш һәм социаль адаптация бозылуларын коррекцияләү өчен махсус педагогик программалар һәм методикалар нигезендә гамәлгә ашыру;

3.1.14. законнарда билгеләнгән тәртиптә мәгариф өлкәсендә дәүләт статистика хисаплылыгын җыю, эшкәртү, анализлау һәм бирүне гамәлгә ашыру;

3.1.15. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә ведомствога караган муниципаль белем бирү учреждениеләренең бюджет һәм бюджеттан тыш эшчәнлеге буенча статистик һәм бухгалтер хисаплылыгын законнарда билгеләнгән срокларда тапшыру;

3.1.16. муниципаль белем бирү учреждениеләре белән оештыру-методик җитәкчелек итүне гамәлгә ашыру; күрсәтелгән учреждениеләрдә белем бирү процессын матди-техник яктан тәэмин итү;

3.1.17. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә дәүләт, муниципаль һәм башка белем бирү учреждениеләренең үзара хезмәттәшлеген һәм координацияләүне тәэмин итү;

3.1.18. балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау эшчәнлегендә законнар һәм муниципаль хокукый актлар нигезендә катнашу;

3.1.19. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшырылган мәгариф өлкәсендә дәүләт вәкаләтләренең үтәлешен тәэмин итү;

3.1.20. Мәгариф идарәсен алып бару өлкәсенә караган мәсьәләләр буенча Башкарма комитетка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы башлыгы, Башкарма комитет җитәкчесе, район Советы карарлары һәм боерыклары проектларын кертү;

3.1.21. үз компетенциясе кысаларында мәгариф идарәсен алып бару өлкәсенә караган мәсьәләләр буенча хокукый актлар кабул итү; мәгариф идарәсен алып бару өлкәсенә караган мәсьәләләр буенча методик материаллар эшләү;

3.1.22. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә мәгариф өлкәсендә законнарны куллану тәҗрибәсен гомумиләштерү, мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга анализ ясау; мәгариф идарәсен алып бару өлкәсенә караган мәсьәләләр буенча муниципаль хокукый актларны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү; мәгариф идарәсе эшчәнлеге өлкәсенә караган мәсьәләләр буенча оператив һәм аналитик материаллар, белешмәләр әзерләү;

3.1.23. Мәгариф идарәсен алып бару өлкәсенә караган мәсьәләләр буенча законнарда һәм (яки) муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, физик һәм юридик затлар белән үзара хезмәттәшлек;

3.1.24. гражданнарны (физик затларны) кабул итүне оештыру, законнар нигезендә мөрәҗәгатьләрне үз вакытында һәм тулысынча карауны тәэмин итү;

3.1.25. үз компетенциясе кысаларында закон тарафыннан саклана торган серне тәшкил итүче мәгълүматларны яклауны тәэмин итү;

3.1.26. Мәгариф идарәсе эшчәнлеге процессында барлыкка килгән архив документларын комплектлау, саклау, исәпкә алу һәм куллану буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә эш башкару;

3.1.27. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының мәгариф идарәсен карап тоту һәм аңа йөкләнгән вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен каралган бюджет акчаларын алучы һәм баш бүлүче функцияләрен башкару;

3.1.28. Мәгариф идарәсендә гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару; Мәгариф идарәсенең мобилизацион әзерлеген тәэмин итү, шулай ук ведомство карамагындагы муниципаль учреждениеләрнең мобилизацион әзерлеге буенча эшчәнлеген контрольдә тоту һәм координацияләү;

3.1.29. ведомство карамагындагы муниципаль учреждениеләргә беркетелгән муниципаль мөлкәтнең сакланышын һәм нәтиҗәлелеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыру;

3.1.30. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының мәгарифне үстерүгә киткән чыгымнар өлешендә бюджет проектын эшләүдә катнашу;

3.1.31. Мәгариф идарәсе хезмәткәрләрен һөнәри әзерләүне, аларны яңадан әзерләүне, квалификацияләрен күтәрүне һәм стажировканы оештыру;

3.1.32. Мәгариф идарәсе компетенциясенә бәйле бәхәсләр һәм башка мәсьәләләр буенча судларда катнашуны тәэмин итү;

3.1.33. законнарда һәм муниципаль хокукый актларда каралган нигезләрдә һәм тәртиптә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

3.2. Билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру максатларында Мәгариф идарәсе хокуклы:

3.2.1. законнарда һәм (яки) муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә Мәгариф идарәсе компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча карарлар кабул итү өчен кирәкле белешмәләрне соратырга һәм алырга;

3.2.2. Мәгариф идарәсе эшчәнлеге өлкәсенә караган мәсьәләләрне эшләү өчен законнарда һәм (яки) муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә, фәнни һәм башка оешмаларны, галимнәрне һәм белгечләрне җәлеп итәргә;

3.2.3. Координация, киңәшмә һәм эксперт органнары (советлар, комиссияләр, төркемнәр, коллегияләр), шул исәптән билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә ведомствоара, булдырырга;

3.2.4. Мәгариф идарәсе эшчәнлеге өлкәсенә караган мәсьәләләр буенча юридик һәм физик затларга аңлатмалар бирергә;

3.2.5. Мәгариф идарәсе бүлекләрен расларга, шулар белән бүләкләү турында карар кабул итәргә һәм башка төр кызыксындыру чаралары кулланырга.

## IV. Мәгариф идарәсе эшчәнлеген оештыру

4.1. Мәгариф идарәсен Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – Мәгариф идарәсе башлыгы (алга таба – Мәгариф идарәсе башлыгы) җитәкли, ул законнар һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә.

Мәгариф идарәсе башлыгына карата эш бирүче вәкаләтләре Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.2. Мәгариф идарәсе башлыгы Мәгариф идарәсенең законнарда, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Уставында, әлеге Нигезләмәдә һәм башка муниципаль хокукый актларда билгеләнгән кысаларда бердәм башлангыч принципларында эшчәнлеге белән җитәкчелек итә.

4.3. Мәгариф идарәсе җитәкчесе Мәгариф идарәсе эшчәнлеген оештыру һәм тәэмин итү буенча түбәндәге функцияләрне башкара:

- Мәгариф идарәсе тарафыннан ул булдырылган максатларның үтәлешен, Мәгариф идарәсенең үз вәкаләтләрен тиешенчә үтәвен тәэмин итә;

- Мәгариф идарәсе исеменнән ышаныч кәгазеннән башка эш итә, аның мәнфәгатьләрен дәүләт хакимияте органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм юридик һәм физик затлар белән үзара мөнәсәбәтләрдә яклый;

- законда, әлеге Нигезләмәдә, органнарның бүтән муниципаль хокукый актларында, хезмәт килешүендә һәм мөлкәтне беркетү турында килешүдә билгеләнгән чикләрдә Мәгариф идарәсе исеменнән аның мөлкәте белән эш итә, муниципаль контрактлар (шартнамәләр) төзи, ышанычнамәләр бирә, шәхси счетлар, банкларда һәм башка кредит оешмаларында исәп-хисап һәм башка счетлар ача;

- Башкарма комитет җитәкчесенә раслау максатыннан бүлеп бирелгән бюджет ассигнованиеләре чикләрендә Мәгариф идарәсенең бюджет сметасын һәм штат расписаниесен кертә;

- законнарда билгеләнгән тәртиптә эш бирүченең муниципаль хезмәткәрләргә һәм мәгариф идарәсенең башка хезмәткәрләренә карата барлык вәкаләтләрен гамәлгә ашыра, шул исәптән хезмәткәрләрне вазыйфага билгели һәм вазыйфадан азат итә, законнар нигезендә дисциплинар түләттерү һәм бүләкләү чараларын куллана; үз компетенциясе кысаларында Мәгариф идарәсенең барлык хезмәткәрләре өчен мәҗбүри булган боерыклар чыгара;

- хисап торышы өчен, билгеләнгән законнар һәм (яисә) муниципаль хокукый актлар нигезендә тиешле органнарга (учреждениеләргә) хисаплылыкны, шул исәптән бухгалтерлык һәм статистика хисапларын үз вакытында һәм тулысынча тапшыру өчен җаваплылык тота;

- ведомство буйсынуындагы муниципаль белем бирү учреждениеләре җитәкчеләрен вазыйфага билгели һәм вазыйфадан азат итә, күрсәтелгән җитәкчеләр белән законнар нигезендә хезмәт шартнамәләрен төзи, үзгәртә һәм өзә;

- муниципаль хезмәт турындагы законнар, муниципаль хокукый актлар нигезендә Мәгариф идарәсендә муниципаль хезмәт үтү белән бәйле мәсьәләләрне хәл итә;

- Башкарма комитетка әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы 3.1.20 пунктчасында күрсәтелгән хокукый актлар һәм башка документлар проектларын кертә;

- әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы 3.1.1 пунктчасы нигезендә хокукый актлар чыгара;

- ведомство карамагындагы муниципаль белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә законнарга һәм муниципаль хокукый актларга каршы килми торган мәҗбүри күрсәтмәләр бирә;

- бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган бюджет законнарының һәм норматив хокукый актларның үтәлешен тәэмин итә;

- законнарда һәм (яисә) муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә Мәгариф идарәсе һәм Мәгариф идарәсенә караган муниципаль белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләрен, Мәгариф идарәсен алып бару өлкәсендә эшчәнлек алып баручы башка затларны мактаулы исемнәр бирүгә һәм дәүләт һәм муниципаль бүләкләр, Мактау грамоталары белән бүләкләүгә, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлардан, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы башлыгыннан, башка муниципаль берәмлекләрнең югары вазыйфаи затларыннан, дәүләт хакимияте органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан рәхмәт белдерү рәвешендә бүләкләүгә тәкъдим итә;

- әлеге Нигезләмәдән килеп чыга торган һәм законнарга каршы килми торган башка функцияләрне башкара.

4.4. Үз хокукларын һәм бурычларын үтәгәндә Мәгариф идарәсе җитәкчесе намус белән һәм акыл белән эш итәргә тиеш. Мәгариф идарәсе башлыгы Мәгариф идарәсе эшенең сыйфаты һәм нәтиҗәлелеге өчен җавап бирә.

Мәгариф идарәсе башлыгы Мәгариф идарәсенә йөкләнгән вәкаләтләрне үтәү өчен шәхси җаваплылык тота.

Мәгариф идарәсе башлыгы Мәгариф идарәсенә аның гаепле гамәлләре (гамәл кылмавы) китергән зыяннары өчен законда билгеләнгән тәртиптә җаваплылык тота.

4.5. Мәгариф идарәсе җитәкчесе вакытлыча булмаганда, аның вазыйфаларын аның урынбасары башкара, ә соңгысы булмаганда – Мәгариф идарәсе башлыгы боерыгы яисә Башкарма комитет җитәкчесе күрсәтмәсе белән билгеләнгән башка зат.

Район Башлыгы урынбасары Р. Ә. Кәримуллина